**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «28» ноябреннән № 298

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең спорт объектларына бушлай йөрү билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле һәм керем китерә торган башка хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 40-325 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләре әгъзаларына, Россия Эчке эшләр министрлыгының Яңа Чишмә районы буенча бүлеге хезмәткәрләренә һәм аларның гаилә әгъзаларына «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең спорт объектларына бушлай йөрү билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов